**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

Коррупциягә каршы көрәшү турында законнарны үтәүгә контрольне көчәйтү максатларында һәм Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәшү турында законнарны үтәүгә контрольне көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы Указы нигезләмәләрен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы һәм 2017 елның 11 февралендәге ПУ-123 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә, 8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрен Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәте аларны Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәтенә тапшыруга каралган срок тәмамланганнан соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсенә җибәрә.».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы һәм 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле $16^6$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$16^6$. Әлеге Нигезләмәнең $16^1$, $16^3$ һәм $16^4$ пунктларында күрсәтелгән дәлилле бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә һәм хәбәрнамәләрдә бирелгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 23, $24^3$, $25^1$ пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 25 мартындагы ПУ-308 номерлы һәм 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктта:

«з» пунктчасында «гражданнар бирә торган белешмәләрнең» сүзләрен «шулай ук гражданнар бирә торган белешмәләрнең (коррупциячел хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлештә)» сүзләренә алмаштырырга;

«л» пунктчасында:

«шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

«, шулай ук әлеге белешмәләргә анализ ясаганда, күрсәтелгән гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре белән, аларның ризалыгы булганда, әңгәмәләр уздыру, алардан үзләренең ризалыгы белән тиешле аңлатмалар алу, Россия Федерациясе прокуратура органнарыннан, башка федераль дәүләт органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәве (дәүләт, банк, салым сере булган белешмәләр һәм закон тарафыннан саклanучы сер булган башка белешмәләр булган мәгълүматтан тыш) турында мәгълүмат алу, гражданнар яисә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре биргән белешмәләрне, алынган башка мәгълүматны тикшерү»;

б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәнең 1 пункты «б» пунктчасында «белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын» сүзләреннән соң «(коррупциячел хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлештә)» сүзләрен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында» 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы һәм 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә, 1 пунктның «б» пунктчасында «белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын» сүзләреннән соң «(коррупциячел хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлештә)» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы

гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2015 елның 2 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә, 1 пунктның «в» пунктчасында «белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын» сүзләреннән соң «(коррупциячел хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлештә)» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 5 декабрендәге ПУ-1163 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-914 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-717 номерлы һәм 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт урынында тәртипкә куелган таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе хакында нигезләмәдә:

$3^1$ пунктта:

икенче абзацта «җиде эш көне» сүзләрен «30 көн» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «45 көн» сүзләрен «60 көн» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа $3^2$ пункты өстәргә:

«$3^2$. Әлеге Нигезләмәнең 3 пункты өченче абзацында күрсәтелгән дәлилле бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаларда һәм хәбәрнамәдә бирелгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә федераль дәүләт органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаларны һәм хәбәрнамәне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре

буенча дәлилле бәяләмә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 15 - $15^2$ пунктлары нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, $3^2$ пунктны $3^3$ пункт дип санарга:

«Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча бәяләмә һәм аның нигезендә кабул ителгән карар Комиссия әгъзаларына Комиссиянең киләсе утырышында белдерелә. Гариза яисә хәбәрнамә җибәргән затка кабул ителгән карар турында аны кабул иткән көннән 15 көн эчендә хәбәр ителергә тиеш.»;

б) Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирүгә кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе хакында нигезләмәдә:

4 пунктта:

икенче абзацта «җиде эш көне» сүзләрен «30 көн» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «45 көн» сүзләрен «60 көн» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункты өстәргә:

«$4^1$. Әлеге Нигезләмәнең 3 пункты икенче абзацында күрсәтелгән дәлилле бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән гаризада бирелгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә федераль дәүләт органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән гаризаны алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 18 пункты нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

6 пунктта:

«Бәяләмә» сүзен «Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча бәяләмә» сүзләренә алмаштырырга;

«җиде эш көне дәвамында» сүзләрен «15 көн дәвамында» сүзләренә алмаштырырга.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 11 декабрь
№ ПУ-1092